| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЕЛАБУЖСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12 май, 2016 ел № 570

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты каршында әтиләр Советын төзү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында әтиләр Советы эшен активлаштыру турында» 2016 елның 10 февралендәге ВШ-12-31 номерлы киңәшмәсе беркетмәсен үтәү йөзеннән һәм гаиләләрнең рухи-әхлакый потенциалын саклап калу һәм үстерү, әти, әни статусына хөрмәт тәрбияләү, балаларны тәрбияләү өчен ата-аналарның җаваплылыгын арттыру, гаилә әгъзаларының иҗади сәләтләрен үстерү максатларында, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты каршында әтиләр Советын төзергә.
2. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты каршында әтиләр Советы турында Нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).
3. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты каршында әтиләр советы составын расларга (2 нче кушымта).
4. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы әтиләр Советы эшчәнлеген массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны тәэмин итүне «Татмедиа» ААҖ филиалына, «Новая Кама» газетасына тәкъдим итәргә.
5. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л.Н. Рыбаковага йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
“______” _______ ____ел
карарына 1 нче кушымта

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты каршында
әтиләр Советы турында Нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты каршында әтиләр Советы (алга таба - Совет) Алабуга муниципаль районының иҗтимагый ата-аналар органы булып тора.

Әлеге Нигезләмә Советның вәкаләтләрен, максатларын, бурычларын, функцияләрен, формалаштыру тәртибен билгели һәм ата – аналар җәмәгатьчелегенең дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары белән социаль-тәрбия тирәлеген яхшырту буенча үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү, балалар, яшүсмерләр һәм гаиләләрне җәлеп итеп, профилактик, агарту, спорт һәм мәдәни - үстерү эшен оештыру, хәрби - патриотик һәм рухи-әхлакый тәрбия бирүне активлаштыру максатларында төзелә.

1.2. Совет нз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты указларына һәм кнрсәтмәләренә, Россия Федерациясе Хөкнмәте карарларына һәм кнрсәтмәләренә, БМОның бала хокуклары турындагы конвенциясенә, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3. Совет үз эшчәнлеген хәбәрдарлык, бәйсезлек, Законлылык принципларына таянып, иҗтимагый башлангычларда гамәлгә ашыра.

1.4. Совет үз эшендә бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау өлкәсендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары, муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре, шулай ук оештыру – хокукый формаларына бәйсез рәвештә, предприятиеләр, оешмалар белән хезмәттәшлек итә.

2. Советның төп максатлары һәм бурычлары

2.1. Совет эшчәнлегенең максаты булып түбәндәгеләр тора:

- әтиләрнең гаилә һәм балаларны тәрбияләү өчен җаваплылыгын һәм статусын күтәрү;

- гаилә институтын һәм гаилә яшәү рәвешен ныгытуда әтиләрнең тырышлыгын берләштерү, рухи – әхлакый традицияләрне һәм гаилә мөнәсәбәтләрен торгызу һәм саклап калу;

- районда гомуми стратегияне һәм балаларның конституциячел хокукларын һәм җаваплы ата-аналарына ярдәм итү буенча дәүләт сәясәтенең өстенлекле юнәлешләрен тормышка ашыру өчен кирәкле шартлар тудыру.

2.2. Совет бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

- баланың хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау;
- гаиләләр белән профилактик эш оештыру;
- гаилә һәм балачак институтларын ныгыту һәм үстерү мәсьәләләрендә ир-атларның эшчәнлеген активлаштыру;
- балалар һәм яшүсмерләрне рухи, әхлакый, мәдәни, физик, хезмәт һәм патриотик тәрбияләү буенча ата-ана җәмәгатьчелегенең педагогик потенциалын көчәйтү, сәламәт яшәү рәвеше культурасын формалаштыру;
- балаларга җәмгыятьтә социаль ярдәм күрсәтү һәм тормышка яраклашу, үз-үзен тотышы булган яшүсмерләр белән эшне оештыру; үз-үзен тотышы булган яшүсмерләр белән эшне оештыру;
- тәрбия процессы белән идарә итүдә мәгариф оешмаларына ярдәм күрсәтү;
- башка социаль институтлар, халыкта ата-ана бурычларын үтәүгә җаваплы мөнәсәбәт формалаштыру буенча иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек итү;
- район территориясендә гаилә сәясәте өлкәсендә оештыру, тәрбия һәм башка чараларны эшләүдә компетенция чикләрендә катнашу;
- җәмгыятьтә гражданлык килешүенә, тотрыклылыкка һәм тынычлыкка ирешү;
- эшчәнлекләре гражданнарның репродуктив сәламәтлеген профилактикалау һәм саклау белән бәйле дәүләт учреждениеләренә ярдәм итү.

## 3. Совет композициясе

3.1. Совет үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен түбәндәге функцияләрне башкара:

гаиләгә, аналарга, аталарга һәм балаларга ярдәм итүгә юнәлтелгән докладлар, планнар әзерләүдә, программалар проектларын һәм башка хокукый актларны әзерләүдә катнаша;

- аталарга, ата-аналарга, гаиләгә һәм балаларга карата социаль сәясәт мәсьәләләре буенча законнарны үзгәртү буенча тәкъдимнәр кертә;
- гаиләнең социаль-икътисадый хәле, гаилә сәясәте, хокукларны, аталыкны һәм балачакны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча муниципаль, төбәк киңәшмәләр, семинарлар һәм башка чаралар әзерләүдә һәм уздыруда катнаша;
- халыкка гаилә, ата булу, ана булу һәм балачак мәнфәгатьләрендә үткәрелә торган сәясәт турында хәбәр итү максатыннан массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек итә;

- массакүләм, сәламәтләндерү, мәдәни, спорт чаралары, социаль акцияләр, авыр тормыш шартларына дучар булган гаиләләргә, «хәвеф-хәтәр төркеме» гаиләләренә ярдәм итү буенча хәйрия эшчәнлеге оештыра;

- Совет максатларына һәм бурычларына караган мәсьәләләр буенча чараларда катнаша;

- халыкның сәламәтлеген саклау, җаваплы ата булу, гаиләгә ярдәм күрсәтү һәм социаль сәясәтне тормышка ашыру өчен җаваплы социаль өлкә хезмәткәрләренең белем дәрәҗәсен күтәрүгә ярдәм итә торган чараларны тормышка ашыра;

аиләгә социаль ярдәм мәсьәләләрен хәл итүдә иҗтимагый берләшмәләр, хәйрия фондлары һәм башка коммерцияле булмаган оешмалар белән хезмәттәшлек итә.

4. Совет эшчәнлеген оештыру.

4.1. Совет иҗтимагый башлангычларда эшләүче рәисдән, урынбасардан һәм аның әгъзаларыннан тора. Совет әгъзаларының гомуми саны 15 кеше. Советның персональ составы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

4.2. Совет составына балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) керә.

4.3. Совет эшчәнлеге җитәкчелеген аның рәисе башкара, ул:

- Совет эше планын раслый;

- Совет әгъзалары арасында функциональ вазыйфаларны бүлә;

- Совет составына яисә аннан аерым әгъзаларын төшереп калдыру турында Алабуга муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенә тәкъдимнәр кертә;

- Совет утырышларын үткәрә.

4.4. Совет рәисе рәисе булмаган очракта аның вәкаләтләрен рәис урынбасары башкара.

4.5. Совет утырышы кирәк булган саен уздырыла, елына кимендә ике тапкыр уздырылырга тиеш. Совет әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, Совет утырышы тулы хокуклы дип санала. Совет утырышы протоколын утырыш секретаре алып бара.

4.6. Утырышлар нәтиҗәләре буенча Совет утырышларда катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән карар кабул итә.

4.7. Совет карары совет рәисе һәм секретаре тарафыннан имзаланган беркетмә белән рәсмиләштерелә. Совет карарлары тәкъдим итү характерында.

4.8. Совет утырышларында аның эшчәнлеген яктырту максатларында массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнаша ала.

4.9. План чараларының үтәлешен Совет рәисе контрольдә тота.

Совет тарафыннан үткәрелә торган планлы чараларның нәтиҗәләре беркетмә, белешмәләр, мәгълүмат рәвешендә рәсмиләштерелә.

4.10. Совет утырышлары беркетмәләре, аның эшчәнлеген регламентлаучы башка документлар рәис карамагында саклана.

4.11. Совет эшчәнлеген туктату аның әгъзаларының күпчелеге инициативасы белән Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең мәҗбүри белдерүе белән гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
“_____” ______ ____ел
карарына 2 нче кушымта

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты каршында этиләр Советы

СОСТАВЫ

| № | Фамилиясе, исеме атасының исеме | Вазыйфасы |
|---|---|---|
| 1. | Зарипов Р.И. | “Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе” МКУ башлыгы, Совет рәисе |
| 2. | Мәрданов Р.И. | АМР Алабуга шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе, Совет рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| 3. | Кәримов Э.Г. | «Балалар иҗаты үзәге» өстәмә белем бирү МБУ директоры, Совет секретаре (килешү буенча) |
| Совет әгъзалары | | |
| 4. | Макаров П.А. | Танай авыл җирлеге башлыгы (килешү буенча) |
| 5. | Әхмәтҗанов Ш.Г. | «АҮРХ» ДАССУ баш табибы (килешү буенча) |
| 6. | Филиппов В.Н. | «АМР торак-коммуналь хуҗалык һәм төзелеш департаменты» МУП директоры (килешү буенча) |
| 7. | Сәфәаров Ш.Г. | АМР Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча урынбасары |
| 8. | Крылов А.М. | “Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм идарәсе” МКУ башлыгы |
| 9. | Кашапов Г.Н. | 5 нче номерлы территориаль иҗтимагый үзидарә рәисе (килешү буенча) |
| 10. | Бахметов А.Б. | АМР Иске Күклек авыл җирлеге башлыгы (килешү буенча) |
| 11. | Шәймарданов И.З. | АМРда кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (килешү буенча) |
| 12. | Базуев С.И. | Россия Эчке эшләр министрлыгының Алабуга муниципаль районы буенча полиция бүлеге башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| 13. | Фазлиәхмәтов Р.Г. | «Алабуга ит-консерв комбинаты» ААҖ генераль директоры (килешү буенча) |
| 14. | Талапин П.С. | «Колос» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы рәисе (килешү буенча) |
| 15. | Шмаков В.Н. | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты 3 нче хокук тәртибен саклауның терәк пунктының баш белгече |